РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2019г. г. Альметьевск №173

Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә еметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге №ММВ-7 8/164@ «Пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның естәмә нигезләрен билгеләү, бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында»гы боерыгы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә еметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба-бурыч):

- җир салымы һәм үлгән физик затлар милкенә булган салым бурычы барлыкка килү срогы еч елдан артып киткән очракта;
- үлгән физик затлар яки үлгән дип исәпләнүче затларның мирас хокукыннан баш тарткан яки варислары булмаган очракта, милек һәм җир салымы буенча;
- җир салымы һәм физик затлар милкенә салым бурычларын түләттерүгә өметсез дип танылу датасы киләсе елның һәр 1 числосына өч елдан артык булган очракта;
- реструктуризацияләү режимында һәм банкротлык процедураларында булган салым түләүчеләрдән тыш (банкротлык), гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хәмидуллин Ф.Р.).

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов

Зак. № 3774